**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Аксубаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Аксубай муниципаль районы башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 11 » 03 2015 № 82

Аксубаево

Автомобиль транспортын карап тотуга норматив чыгымнар турында

«Автомобиль транспортын карап тотуга норматив чыгымнар турында» 29.01.2015 ел, № 46 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.2015 елга беркетүләрне расларга:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль автономияле, бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтүче җиңел автомобильләрне тотуга норматив чыгымнар;

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарына хезмәт күрсәтүче җиңел автомобильләрнең, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль автономияле, бюджет учреждениеләренең тәүлеклек узышы нормативлары;

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль автономияле, бюджет учреждениеләрендә шәхси җиңел автомобильне хезмәт максатларында кулланганда компенсациянең чик күләме;

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы җирле үзидарә органнарына, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль автономияле, бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтүче җиңел автомобильләрне тотуга норматив чыгымнар, аларны йөртүчеләрсез кулланганда;

җиңел автомобильләрне, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының җирле үзидарә органнарын, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль автономияле, бюджет учреждениеләрен тоту, фаразлау һәм командировка чыгымнарын планлаштыру өчен норматив чыгымнарга артыклык коэффициенты.

2.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының муниципаль автономияле, бюджет учреждениеләренә хезмәт күрсәтүче автотранспорт чараларын

тоту чыгымнары әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән норматив чыгымнар күләмендә, учреждениеләргә муниципаль йөкләмәнең үтәлешен финанс белән тәэмин итүгә бүлеп бирелә торган акчалар, шулай ук түләүле хезмәтләр күрсәткәндә һәм керем китерә торган бүтән эшчәнлек алып барганда учреждениеләр тарафыннан алына торган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3.Вазыйфаи затларга маркалар буенча хезмәт җиңел автомобильләрен конкретлаштыру Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Башкарма комитеты күрсәтмәсе белән билгеләнә.

4.Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга http://aksubayevo.tatarstan.ru

Башкарма комитет житәкчесе А. Ф. Горбунов